**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 3 августындагы 2756 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2017 елның 3 апрелендәге 961 номерлы**
**«Административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау, мәҗбүри алынган коралларны (предметларны) һәм документларны бирү һәм юк итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнар, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.3.1, 27.10, 28.3 статьялары, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 28 декабрендәге 11717 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге хакында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарында урамда сәүдә итүне һәм хезмәтләр күрсәтүне оештыру таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту, мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) саклау һәм юк итү буенча чараларны гамәлгә ашыруның бердәм тәртибен билгеләү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 3 апрелендәге 961 номерлы «Административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри

алу, саклау, мәҗбүри алынган коралларны (предметларны) һәм документларны бирү һәм юк итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 9 сентябрендәге 3166 номерлы, 2019 елның 19 сентябрендәге 3323 номерлы, 2025 елның 2 октябрендәге 3323 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбуланы түбәндәге редакциядә бирергә:

«2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнар, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.3.1, 27.10, 28.3 статьялары, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 28 декабрендәге 11717 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге хакында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарында Казан шәһәре территориясендә урамда сәүдә итүне һәм хезмәтләр күрсәтүне оештыру таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту, мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) саклау һәм юк итү буенча чараларны гамәлгә ашыруның бердәм тәртибен билгеләү максатыннан **карар бирәм**:»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 1(1) пункт өстәргә:

«1(1). Урамда сәүдә итүне һәм хезмәтләр күрсәтүне оештыру таләпләрен бозган өчен, административ хокук бозуны кылу кораллары яки предметлары булып торган әйберләрне һәм документларны мәҗбүри алганда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча вәкаләтле затлар итеп Казан шәһәре районнары администрацияләренең Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 28 декабрендәге 11717 номерлы карары белән вәкаләтләр бирелгән вазифаи затларын билгеләргә»;

1.3. түбәндәге эчтәлекле 3(2) пункт өстәргә:

«3(2). Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе турында нигезләмәне әлеге карарга

4 номерлы кушымта нигезендә расларга»;

1.4. 1 номерлы кушымтада:

1.4.1. II бүлекнең 2.4 пунктына «махсус бүлмәгә» сүзләреннән соң «, яки аны алмаштыручы зат» сүзләрен өстәргә;

1.4.2. III бүлекнең 3.2 пунктында «әлеге инструкциянең» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең» сүзләре белән алыштырырга;

1.4.3. III бүлекнең 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.5. Мәҗбүри алынган әйберләрнең һәм документларның хуҗасы административ хокук бозу турындагы эш буенча кабул ителгән карар гамәлгә кергән көннән алып 30 көн эчендә мәҗбүри алынган әйберләрне һәм документларны кире кайтару турында гариза белән мөрәҗәгать итмәсә яки мәҗбүри алынган әйберләрдән һәм документлардан язма рәвештә баш тартса, яисә мәҗбүри алынган әйберләрне һәм документларны бирү турында гариза җибәрелгәннән соң аларны алырга килмәсә, Район (районнар) администрациясе мәҗбүри алынган әйберләрне һәм документларны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән каралган тәртиптә муниципаль милеккә күчерү буенча гамәлләр башкара»;

1.4.4. Административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм административ эш буенча дәлил буларак әһәмияткә ия документларны мәҗбүри алу, саклау, мәҗбүри алынган коралларны (предметларны) һәм документларны бирү һәм юк итү тәртибе турында нигезләмәгә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә;

1.5. 2 номерлы кушымтада «Мәҗбүри алынган милекне күчерү һәм саклау белән бәйле чыгымнар суммасын исәпләү:» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 3 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә;

1.7. әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә редакцияләнгән 4 номерлы кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 3 августындагы
2756 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын яки предметларын исәпкә алу буенча**
**________________ номерлы журнал**

__________________________________________________
(бүлекчә атамасы)

Башланган: 20__ елның «__» __________ ________ номерлы том
Тәмамланган: 20__ елның «__» __________ __________ биттә

<table>
<tr>
<td rowspan="2">№ т/б</td>
<td rowspan="2">Беркетмәнең номеры һәм датасы, беркетмә төзелгән зат турында мәгълүмат</td>
<td rowspan="2">Административ хокук бозу коралларын (предметларын) мәҗбүри алуны гамәлгә ашырган затның вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме</td>
<td rowspan="2">Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) кабул итү датасы, саклау урыны</td>
<td rowspan="2">Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларының (предметларының) һәм документларның атамасы, саны (авырлыгы, күләме), төргәге турында мәгълүмат</td>
<td colspan="2">Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм документларны саклауга тапшырган затның вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы, аларны саклауга кабул итеп алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы</td>
<td colspan="2">Мәҗбүри алынган әйберләрне хуҗасына бирү (кайтару) датасы, административ хокук бозу коралларын (предметларын) һәм документларны алган зат турында мәгълүмат, аларны биргән зат турында мәгълүмат, имзалар</td>
<td rowspan="2">Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметлар-ын) һәм документлар-ны юк итү турында карар (дата, кем тарафыннан кабул ителгән)</td>
<td rowspan="2">Администра-тив хокук бозу коралларын (предметла-рын) юк итү турында акт датасы</td>
<td rowspan="2">Искәрмә</td>
</tr>
<tr>
<td>тапшырды</td>
<td>кабул итеп алды</td>
<td>бирде</td>
<td>алды</td>
</tr>
<tr>
<td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td colspan="2">6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td>
</tr>
<tr>
<td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td>
</tr>
</table>

_________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 3 августындагы
2756 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе** – Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары;

**Комиссия рәисе урынбасары** – Казан шәһәре Башкарма комитетының Куллланучылар базары комитеты рәисе;

**Комиссия сәркатибе** – территориясендә рөхсәтсез сәүдә итүне туктату буенча чаралар үткәрелгән Казан шәһәре Башкарма комитеты районы (районнары) администрациясе хезмәткәре;

**Комиссия әгъзалары:**

территориясендә (территорияләрендә) рөхсәтсез сәүдә итүне туктату буенча чаралар үткәрелгән Казан шәһәре Башкарма комитеты районы (районнары) администрациясе башлыгы;

территориясендә (территорияләрендә) рөхсәтсез сәүдә итүне туктату буенча чаралар үткәрелгән Казан шәһәре Башкарма комитеты районы (районнары) администрациясе башлыгы урынбасары;

Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының җәмәгать куркынычсызлыгы мәсьәләләре һәм хокук саклау органнары белән үзара бәйләнешләр идарәсе башлыгы (ихтыяҗ булганда);

Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы (ихтыяҗ булганда);

Казан шәһәре Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе башлыгы (ихтыяҗ булганда);

«Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры (ихтыяҗ булганда);

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Казан шәһәренең участок буенча вәкаләтле полиция хезмәткәрләре һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча).

Комиссия әгъзаларының персональ составы территориясендә (территорияләрендә) рөхсәтсез сәүдә итүне туктату буенча чаралар үткәрелгән Казан шәһәре Башкарма комитеты районы (районнары) администрациясе башлыгы карары белән раслана.

———

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 3 августындагы
2756 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

# Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) рөхсәтсез сәүдә итү предметы булган мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү (утильләштерү) турында карарлар кабул итү максатыннан оештырыла.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Гражданлык кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнарга, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.3.1, 27.10, 28.3 статьяларына, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 28 декабрендәге 11717 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге хакында»гы карарына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, Казан шәһәре территориясендә урамда сәүдә итүне һәм хезмәтләр күрсәтүне оештыру таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту чараларын гамәлгә ашыру тәртибенә, шулай ук әлеге Нигезләмгә таяна.

## II. Комиссиянең төп бурычы

2.1. Комиссиянең төп бурычы – мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын), шул исәптән рөхсәт ителмәгән сәүдә предметы булып торган сыйфатсыз һәм (яки) куркыныч азык-төлек продукциясен утильләштерү (юк итү) турында Комиссия белән берлектә карар кабул итү.

## III. Комиссиянең хокуклары

3.1. Комиссия үз вәкаләтләренә караган мәсьәләләрне карап тикшерү һәм хәл итү өчен кирәкле мәгълүматны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә компетентлы органнардан соратып алырга хокуклы.

## IV. Комиссия эшчәнлеген оештыру

4.1. Комиссия белән – Комиссия рәисе, ул булмаган очракта, Комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

Комиссия сәркатибе функцияләрен Казан шәһәренең территориясендә рөхсәт ителмәгән сәүдәне туктату буенча чаралар уздырылган районы (районнары) администрациясе хезмәткәре башкара.

4.2. Комиссия рәисе үзенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә:

- Комиссия эше белән җитәкчелек итә;
- Комиссия утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- Комиссия утырышларында рәислек итә;
- Комиссия әгъзалары арасында вазифаларны бүлә;
- Комиссия утырышының көн тәртибенә тәкъдимнәр кертә;
- Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыра;
- документларны, шул исәптән Комиссия утырышлары беркетмәләрен имзалый;
- Комиссия утырышларында хәлиткеч тавыш хокукына ия.

4.3. Комиссия рәисе урынбасары:

- Комиссия тарафыннан карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә;
- Комиссия тарафыннан карап тикшерелә торган мәсьәләләргә кагылышлы материаллар белән таныша;
- Комиссия һәм аның рәисенең йөкләмәләрен үти;

- Комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазифаларын башкара.

4.4. Комиссия әгъзалары:

- Комиссия утырышының көн тәртибенә тәкъдимнәр кертәләр;

- Комиссия тарафыннан карап тикшерелә торган мәсьәләләргә кагылышлы материаллар белән танышалар;

- Комиссия һәм аның рәисенең йөкләмәләрен үтиләр;

- Комиссия утырышы мәсьәләләрен әзерләүдә катнашалар һәм аның карарларын үтәү өчен кирәкле чараларны гамәлгә ашыралар;

- Комиссия утырышларында үз вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча чыгышлар ясыйлар.

4.5. Ихтыяҗ булган очракта, Комиссия утырышларында катнашу өчен Комиссия әгъзалары булып тормаган хокук саклау, күзәтчелек органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.6. Комиссия сәркатибе:

- кирәкле документларны рәсмиләштерүне һәм җибәрүне, Комиссия әгъзаларына Комиссия тарафыннан карап тикшереләчәк барлык мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирүне дә кертеп, Комиссия утырышларын әзерләүне гамәлгә ашыра, шул исәптән утырышка кимендә 3 эш көне кала Комиссия әгъзаларына утырышны үткәрү датасы, вакыты, урыны турында хәбәр итә һәм аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

- Комиссия утырышында катнашучы затлар турында белешмәләрне теркәп, Комиссия утырышы беркетмәсен тутыра;

- Комиссия эшчәнлеге белән бәйле документацияне саклауны тәэмин итә;

- Комиссия рәисе һәм Комиссия рәисе урынбасары йөкләмәсе буенча Комиссия эшчәнлеген тәэмин итүче башка кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашыра.

4.7. Комиссия утырышлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.10 статьясындагы 1 өлеше, 28.3 статьясындагы 6 өлеше нигезендә мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын), шул исәптән рөхсәт ителмәгән сәүдә предметы булып торган сыйфатсыз һәм (яки) куркыныч азык-төлек продукциясен утильләштерү (юк итү) турында карарлар кабул итү зарурлыгы булганда уздырыла.

4.8. Утырышта Комиссия әгъзалары тыңланыла.

4.9. Комиссия утырышы, Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыграгы катнашкан очракта, тулы хокуклы булып санала.

4.10. Карар ачык тавыш бирү юлы белән, Комиссиянең утырышта

катнашкан әгъзаларының гомуми саныннан чыгып, күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4.11. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез бүленгән очракта, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

4.12. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

________

Мәҗбүри алынган
административ хокук бозу
коралларын (предметларын)
юк итү комиссиясе турында
нигезләмәгә кушымта
(Форма)

**Мәҗбүри алынган административ хокук бозу коралларын (предметларын) юк итү комиссиясе беркетмәсе**

20_ елның «___»_______________ Казан шәһәре, ___________, ___ йорт

(беркетмә төзү датасы һәм урыны)

**Катнаштылар:**
**Комиссия рәисе** ________________________________________
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
**Комиссия рәисе урынбасары** ________________________________________
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
**Комиссия сәркатибе:** ________________________________________
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
**Комиссия әгъзалары:**

__________________________
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Көн тәртибе:**

__________________________________________________________________________

**Тыңландылар:** докладчы

________________________________
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Тавыш бирделәр ----------«әйе» дип җавап бирүчеләр, ------------«каршы» дип җавап бирүчеләр, ------------тавыш бирүдән тыелучылар**
**Комиссия карар бирде:**

________________________________________________________________________________

**Комиссия рәисе** ________________________________________
(имза) (инициаллар, фамилия)
**Комиссия сәркатибе** ________________________________________
(имза) (инициаллар, фамилия)
**Комиссия әгъзалары**

______________________ ________________________________
(имза) (инициаллар, фамилия)